

Урып-жыю кампаниясенен барышы, шулай ук азык-толек базарындагы хәл турында Россия Федерациясе Авыл хужалыгы министрлыгында узган оператив штаб утырышында фикер алыштылар. Министрнын беренче урынбасары Джамбулат Хатуов рәислегендә узган чарада федераль ведомстволар, АПК идарәсенен тобәк органнары, тармак берлекләре һәм оешмалар вәкилләре катнашты. Мордовия Республикасыннан утырыш эшендә авыл хужалыгы һәм азык-толек министры урынбасары Иван Учайкин һәм министрлыкнын жаваплы хезмәткәрләре катнашты.      Россия тобәкләренен кvбесе урып-жыю процессына кушыла. Бvгенге кондә 34,9 млн. тонна ашлык суктырылган, ил буенча тулаем уныш кvрсәткечләре узган ел дәрәжәсеннән артып китә. Мордовиядә дә аграрийларыбызнын кызу вакыты. Шулай, 26 июльгә Мор-довиядә урып-жыю кампаниясенә респуб-ликанын барлык муниципаль районында-гы авыл хужалыгы предприятиеләре кушылды. Алар гектарыннан уртача 26,2 центнер (vткән елдан -14, 7 цга кимрәк) уныш белән 374,6 мен тонна ашлык жыеп алганнар инде. Агымдагы сезонда республика игенчеләренә 464,4 мен га мәйданнан бортекле һәм кузаклы культураларны (кукуруздан башка) жыеп алырга кирәк булачак. Аграрийлар урак белән бер vк вакытта эре могезле терлек очен азык әзерләv, 2022 ел унышы очен туфрак әзерләv белән мәшгуль. Әйтеп китәргә кирәк, 21 июльдә Мордовиядә яшел борчак эшкәртv сезоны тәмамланды. «Саранский» консервалар заводы 3,8 мен тонна чимал эшкәрткән.